**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

Ленин пр.,17йорт,Актаныш ав.,423740

Тел. (85552)3-44-22,факс(85552) 3-44-14,E-mail:aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

________________ № ______

«2020-2022 елларга Актаныш муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасы турында» Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2020 елның 30 апрелендәге ПР-85 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 20 гыйнварендәге 68-р номерлы, 2020 елның 21 декабрендәге 2859-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 30 апрелендәге ПР-85 номерлы карары белән расланган «2020-2022 елларга Актаныш муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасы кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

9 һәм 10 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 9 | Муниципаль спорт мәктәпләренең спорт командаларының хоккей буенча Татарстан Республикасы чемпионатында һәм (яки) хоккей буенча Россия Федерациясе чемпионатында (А төркемчәсе) спорт әзерлеге һәм катнашуы программаларын гамәлгә ашыру | ТР Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, ТР АМР «Лачын» спорт мәктәбе МАУ | 2020-2022 | РБ | 392,4 | 401,9 | - |
| 10 | Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмаларын җиһазлау өчен спорт җиһазлары, кием һәм инвентарь сатып алу | ТР АМР «Лачын» спорт мәктәбе МАУ, «Спорт мәктәбе» МБУ, яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | 2020-2022 | РБ | 390,3 | 427,45 | - |

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә:http://pravo.tatarstan.ru, Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында: http:/aktanysh.tatarstan.ru үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары Л.Р.Сираевага йөкләргә.

Җитәкче И.И.Габдулхаев